МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

10.03.2020 г. Казань № 202-осн

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары нигезендә, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга, шул исәптән урман утыртмаларына яисә урман утыртмаларына кертелмәгән агачларга, куакларга һәм лианаларга (алга таба – урманнар) китерелгән зыян күләмен ачыклау максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен кушымтада бирелгән чыгым нормативларын расларга.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карарында билгеләнгән таксалар нигезендә, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен чәчкеннәр һәм кәлшәләр үстерүгә, урман культуралары, урман орлыкчылыгы һәм плюс агачларының вегетатив токымнарыннан плантацияләр, табигый шытып чыккан яшь үсентеләр булдыруга һәм аларны карап тотуга, шытымнарны саклауга, территорияне (агач киселгән урыннарны) кисенте калдыкларыннан, көнкүреш һәм төзелеш калдыкларыннан чистартуга һәм алга таба куллану өчен яраклы торышка китерүгә, урман корылышы һәм урман хуҗалыгы билгеләре ясауга һәм урнаштыруга, урман юлларындагы яки янгынга каршы билгеләнештәге юлларда җитешсезлекләрне бетерүгә, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар коруга бәйле чыгымнар күләменнән чыгып исәпләгән очракта, хокук бозу вакытында гамәлдә булган, әлеге боерыкта билгеләнгән чыгым нормативлары кулланыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә – федераль

дәүләт урман күзәтчелеген, урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урманчылыкларга, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләгәндә әлеге боерыкка таянып эш итәргә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары И.Н. Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының елның 10.03.2020 202-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативлары

| Тәртип саны | Эшләр төре | Үлчәү берәмлеге | Күләме | Чыгымнар, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Урман хуҗалыгы билгеләре (озынлыгы 1,8 м, диаметры 12-16 см булган бүлге баганалары) әзерләү һәм урнаштыру | данә | 1,0 | 1537,15 |
| 2. | Урман корылышы билгеләре әзерләү һәм урнаштыру (Урында үсә торган урманнан 2,3 метр озынлыгында һәм кимендә 22 см диаметрлы квартал баганалары әзерләү һәм урнаштыру) | данә | 1,0 | 1927,88 |
| 3. | Территорияне (агач киселгән урыннарны) чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы торышка китерү | кбм | 1,0 | 122,20 |
| 4. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 2 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 1,9 |
| 5. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 3 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 2,02 |
| 6. | Ябык тамыр системасы белән кәлшәләр үстерү | данә | 1,0 | 10,25 |
| 7. | Агач киселгән урыннарда буразналарга утыртып, 3 яшенә кадәр урман культуралары булдыру | га | 1,0 | 56046,58 |
| 8. | Агач киселгән урыннарда буразналарга утыртып, 4-5 яшенә кадәр урман культуралары булдыру | га | 1,0 | 62844,89 |
| 9. | Агач киселгән урыннарда буразналарга утыртып, 6 яшьтән 10 яшенә кадәр урман культуралары булдыру | га | 1,0 | 87046,6 |
| 10. | Агач кисү планлаштырылган урыннарда һәм киселгән урыннарда туфрак өслеген минераллаштыру юлы белән урманның табигый торгызылуына булышлык итү | га | 1,0 | 2301,76 |
| 11. | Урманның табигый торгызылуына булышлык күрсәтү чаралары белән шытым саклау | га | 1,0 | 4261,46 |
| 12. | Урман орлыкчылыгы плантациясе булдыру | га | 1,0 | 116265,5 |
| 13. | Урман орлыкчылыгы плантацияләрен карап тоту, карап тотуның һәр елы өчен | га | 1,0 | 17910,57 |
| 14. | Территорияне төзелмәләрдән, умарталардан чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы торышка китерү | га | 1,0 | 104786,87 |
| 15. | Территорияне коммуналь-көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары чүп-чарыннан арындыру | кбм | 1,0 | 1300,13 |
| 16. | Урман юлындагы җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 35874,61 |
| 17. | Янгынга каршы билгеләнештәге юлда җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 30498,23 |